| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2015 Казан ш. № 10-9/кс

***2015 елга «Чистай- Водоканал» АҖе өчен эчәргә яраклы суга һәм су агызуга тарифлар билгеләү турында***

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, тарифлар буенча Федераль хезмәтнең «2015 елга су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә гамәлдәге тарифларны үзгәртүнең мөмкин булган максималь чик индексларын уртача Россия Федерациясе субъектлары буенча билгеләү турында» 2014 елның 11 октябрендәге 228-э/4 санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Чистай- Водоканал» АҖе өчен эчәргә яраклы суга һәм су агызуга тарифларны, календарь чорларына бүлеп, әлеге карар кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2015 елның 1 июленнән 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Чистай- Водоканал» АҖенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты рәисе вазифаларын башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча Дәүләт комитеты
карарына кушымта
29.05.2015 № 10-9/кс

«Чистай- Водоканал» АҖе өчен
2015 елга, календарь чорларына бүлеп, эчәргә яраклы суга һәм су агызуга тарифлар

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүче һәм (яисә) су агызуны башкаручы оешмалар, муниципаль берәмлекләр атамасы | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы) сум/куб.м | Су агызуга тариф (бер ставкалы) сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | | 2015 елның 1 июленнән 2015 елның 31 декабренә кадәр | 2015 елның 1 июленнән 2015 елның 31 декабренә кадәр |
| | Чистай муниципаль районы | | |
| 1 | «Чистай- Водоканал» АҖе | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 30,15 | 34,76 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | 25,55 | 29,46 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 маддәсе 6 пунктын гамәлгә ашыру максатыннан чыгып бүлеп бирелә

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге